# Кайбыч мэктэбе

# тарихы



Төзүчеләре: “Туган якны өйрәнү” түгәрәге әгъзәләре.

1774 нче елны Олы Кайбычтан Уракай исемле бер кеше килеп шушы Кайбыч дигән авылда яши башлаган. Шуна курә бу авылны Кайбыч дип атаганнар. Ул килгәәчегә кадәр монда нугайлар яшәгәннәр. Ләкин алар Е.Пугачев тарафыннан туздырылганнар, шуна бу урында беркем дә калмаган була. Һәм Кайбыч исемле кешедән бу авылның нәсел башлары башланып киткән дә инде.

Кайбыч авылындагы мәктәпләр тарихына килик. Хәзерге Тынычлык урамының көнчыгыш ягында мәчет була. Революциягә кадәр монда гарәп телендә дини дәресләр укытыла. Ә революциядән сон, бу мәчет манарасы киселеп, мәдрәсәгә әйләнә. Анда латин хәрефләре белән укытылган (1938-1939 елларда латин бетеп, рус хәрефләренә(кириллицага кучәләр). 1936 елда мәдрәсәне сутәләр. Һәм көнбатыш якка (иске мәктәп урынында) тәрәзәләрен көньякка (хәзерге стадион ягына) каратып дуртеллык мәктәп салына.( Болар - 34 ел Кайбыч мәктәбендә техник хезмәткәр булып эшләгән Хасанова Сыруҗиан Әбзал кызы сөйләүләреннән язып алынды). Сыруҗиан апа әйтүенчә, өсләргә кияргә кием юк, яланаяк мәктәпкә бардык, ди. Беренче укытучыбыз да, мәктәп директоры да – Боерган авылы кешесе, Шәрәфетдинов Галимҗан Шәрәфетдин улы, иде ди. Сыруҗиан апа. Шулай ук Яльчик районы Сериле авлыннан Ильясов Закир абый да укыта ( Галия исемле кызы, югары белемле, Башкириядә яши. Авылга кайтып әтисе эшләгән авылны күреп тә киткән). Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, Галимҗан абыйны да, Закир абыйны да сугышка алалар. Укытучы булып Чупрәле районы Кәкерле авылыннан Гөлҗихан апа килә. Директор вазифасын Кайбыч авылы кешесе -Галимов Рафыйк Захит улы башкара. Беренче Бөтендөнья сугышы тәмамлангач, Закир абый сугыштан кайта алмый (үлеп кала), ә Галимҗан абыйга әйләнеп кайтырга насыйп була. Кайткач, ул янадан директор вазифасын башкара. Ә Рафыйк абыйны Буага райкомга алалар.Авыл мәдрәсәсен тәмамлаучылар: Захит, Харис бабай, Закиров Харис, Гарипов Хэлим һ.б.

1947 -1948 уку елларында башлангыч сыйныфларда Камаретдинова Кәшифә, Нафикова Галия, Бикмуллина Тәгъзимэ апалар укыта.

1951 елнын жәй башында шул ук урынга, ләкин тәрәзәләрен урамга( юлга) каратып җидееллык мәктәп төзелэ башлый.



Бу мәктәпне салдыру өчен, шушы елның 31 августында, элек Норлат мәктәбендә директор булып эшләгән, Гарипов Хәлим Гарип улы күчерелә. Ул вакытта бу вазифага билгеләгәндә, колхоздан рөхсәт кәгазе белән һәм җентекләп тикшерелә торган булганнр. Укучылар бу вакытта клубларда, пункт биналарында укыганнар. Бөтен халык көче белән шул елның көз (октябрь – ноябрь) айларында җидееллык мәктәп өлгерә. Директоры булып Гарипов Хәлим абый билгеләнә, шулай ук тарих дәресләрен дә укыта.



Бу мәктәпне ягып җылыту өчен мәктәптә эшләүче барлык кеше дә урман кисәргә җибәрелә. Ул вакытта машиналар бик аз була. Шуна урманны күбесенчә атларда ташыганнар. Аннары аны кисеп, ярып, ташып куярга да кирәк булган. Бу эшләр кубесенчә төнлэ эшләнгән. 16 -17 яшьлек , техник хезмәткәр булып эшләгән, кыз сәг.иртәнге 4 тә килеп, мәктәпне ачып, мичләр яга идек, дип сөйли Сыруҗиан апа. Бу вакытта мәктәптә эшләүче укытучылардан: Бикмуллина Тәгъзимә, Камартдинова Кәшифә, биологиядән Сабитова Сания, физкультурадан Габитов Әбрар, математикадан Закирова Сания, Закиров Мәсхут. Укытучылар Багаутдинов Камил, Багаутдинова Бану, пионервожатый Галиуллина Гөлҗиһан, рәсемнән Рәмиев Җәүдәт, немец теленнән Мингазова Рузинә һ.б.

1951 -1961 елларда, Кайбыч җидееллык мәктәптә, директор вазифасын башкарган – Гарипов Хәлим Гарипович. 1901 елның 22 апрелендә элеккеге Сембер губернасының Буа өязе Иске Суксу волосте Кайбыч авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1909 – 1915 елларда авыл мәдрәсәсендә укый. 1920 елда ул Совет Армиясе сафына чакырыла. Шуннан Польша фронтына озатыла. 18нче укчы дивизиянең 399нчы укчы полкына барып кушыла. 1921 елда Украинадагы банда, 1922 елда Төркестандагы басмачыларны бетерудә катнаша, аннан малярия белән авырып кайта. 1925 елда профсоюзга керә.1928 елда Горький шәһәренә курссларга укырга җибәрелә. Горький өлкәсе Балахна шәһәренә татар эшчеләрен яңа әдипчә өйрәтү эшенә куела. 1930 елларда авылга кайтып, колхоз тезүдә актив катнаша. 1934 елда Бикмураз авылына мәктәп директоры итеп күчерелә. 1935 елда РОНО да инспектор булып эшли һәм шул ук елны җидееллык мәктәптә тарих фәне укыту буенча хәзерлек өчен Казанга җибәрелә.Курссны бетергәннән соң Норлат җидееллык мәктәбе директоры итеп билгеләнә. Шуннан армия сафына, хәрби училещага чакырыла. Лейтинат званиясе бирелә, фронтка җибәрелә. Ул 270нче укчы дивизиянең 997нче укчы полкы командир взвода булып сугышта йөри. 1943 елны авыр яралана, 4-яра, аның берсе җилкәдән кереп авызыннан биш тешен җимереп чыга. Эвака госпиталендә дәваланып чыккач, яңадан сугышка китә. Икенче тапкыр яраланып, яңадан Эвака госпиталендә дәвалана. Терелеп чыккач, транспортный ротада хезмәт итә. Сугыштан зур бүләкләр белән кайта. Мәсәлән: Икенче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл йолдыз ордены, «Германияне җиңү» һәм «Германияне җиңүгә 20 ел» медальләре белән бүләкләнә. Сугыштан кайтып, 1945 – 1949 елларда Кайбыч мәктәбе мөдире булып эшли. 1949 – 1951 елга кадәр Норлат мәктәбендә эшли. 1951 елда Кайбыч авылында яңа мәктәп салу өчен директор итеп күчерелә. Директор булу белән бергә авылда парторг булып та эшли. Шулай итеп, 15 ел парторг, 30 ел укытучы, 23 ел мәктәп директоры

булып эшли. Хезмэттәге эшләре өчен «За трудовой доблесть», «За трудовое отличие» медальләре белән бүләкләнә. 1961 елны - 60 яшь тулу көнедә аның эшенә зур бәя биреп лаеклы ялга озатыла.Һәм аннан соң да ул мәктәп, авыл тормышында актив катнаша. Авылның тарихын язуда искиткеч зур көч куя. Бөтен фактик материалларны җыеп ул тарихи документларны киләчәк буын өчен калдыра. Ул шулай ук дәресләре белән генә тугел, мәктәп тормышында да зур эшләр эшли. Шул елларда зур гына мәктәп яны бакчасы булдырыла. Оста бакчачы Султеев Расых абый белән биолог Ахметова Венера апаның да бу бакчада өлешләре зур була. Мәктәп бинасы култыгында Хэлим абый водоем ясата. Бу вакытта кирпеч һэм ташлар булмаганга кабер өслэреннэн (мэктэп иске зираят өстендә салынган була) җыеп алынып ясала бу водоем Аңа 200 л.лы 35 бочка су сыя торган була. Моңа хәзерге Норлат купере яныннан су ташыганнар. Шушы бакчада үстерелгән уңыш укучыларның үзләренә булган. Артыгын Файзуллин Садрислам ат жигеп, техник хезмәткәрләр белән тирә-якка сатып йөри торган булганнар.

1961 – 1986 елларда Кайбыч мәктәп директоры булып Сунгатуллин Тәлгат Шакирович эшли. Талгат Шакир улы 1929 елның 5 мартында Яльчек районы Сериле ( Шимурзино-Суренский ) авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Сериле җидееллык мәктәбен бишле билгеләренә генә тәмамлый. 1944 елда Батыр пед. училищесенә укырга керә. Аны тәмамлап 1947 елда Яльчек районы Бикшек авылына укытырга җибәрелә. Башлангыч мәктәптә узенең беренче укытучысы Асия апа ( керәшен булган - Агния Агафонова) була. Биш ел эшләгәч Хезмәтен бәяләп мәктәп җитәкчесе итеп куялар. Мәктәптә сигез ел ярым эшли. Бу мәктәптән зур кешеләр чыкты, дип искә ала, Тәлгат абый. Мәсәлән: Яльчек районында югары судья – Минсәит, Кипячев – Буа шикәр заводы директоры, Бурнашева Флера – Ф.Бурнашның туганы һ.б.



1950 елның 1 апрелендә армия сафларына китә. Украинанын Харьков шәһәрендә хезмәт итә. Армиядән грамоталар белән кайта, Комсомол грамотасы (полкта 3 генә кеше бүләкләнә, писарь була) ,«За отличные показатели в боевой и политической подгатовке 1952 год 9 января, первый секретарь комсомола Михайлов», «Похвальный лист . 1953 год октябрь».Кайткач, военкомат янәдән Бишкекка билгели. 1954 елда читтән торып Казан пед. институтның РТО булегенә укырга керә.

1959 елның февралендә Кайбыч мәктәбенә рус теле укытучысы булып килә. Сультеев Расыйх абый ат белән барып ала, чөнки мәктәптә рус теле дурт ай укытылмаган була. Шушы елны Тәлгат абый институтны тәмамлый. Ел ярым мәктәптә гади укытучы булып эшләгәч, 1961 елның 31 августында, Кайбыч җидееллык мәәтәбендә директор итеп куялар.

1972 елның сентябрь аенда мәктәп яны интернаты ачыла. Аны ачуда Сунгатуллин Тәлгат Шакир улының хезмәте зур була. Монда Югары Наратбаш авылыннан килеп укып йөрүче 12 - 20ләп бала яши. Беренче тәрбияче – Шарипзянова Гөлзидә була. Шул ук елның октябрь аенда тәрбияче итеп Сабирова Сария Садри кызы билгеләнә. Интернатта повар булып, Гыйззатуллина Сания белән Маннапова Бибинур, төнге няня булып, Шәмсиева Зөбэрҗәт белән Фахрутдинова Әхликамал, кер юучы булып, Нигъматуллина Нурзидә апалар эшли. Балалар көндәлек кайнар аш белән тәэмин ителәләр. Шулай ук төрле кичәләр, бәйрәмнәр, яңа ел, 23 февраль, сигезенче март бәйрәмнәре бик күңелле итеп үткәрелә. Клубларга, китапханәләргә, киноларга культпоходлар даими оештырыла. Интернат 1984 елда ябыла.

Мәктәп - 1980 елда сигезеллыкка, 1982 елда урта мәктәпкә әйләнә. Авылда яңа мәктәп төзү идеясе планлаштырыла. Нәкъ шушы идеяне тормышка ашыруда да Тәлгат Шакир улының, шушы елларда эшләүче укытучыларның, укучыларның хезмәтләре зур була. 1984 елда Тынычлык урамындагы хәзерге яна мэктэп сафка баса. Мәктәпне ачуда шул еллардагы РОНО җитәкчесе Малышев Н.И. катнаша.



1986 елда Тәлгат абый уз теләге белән директор вазифасыннан китә. Һәм ике ел гади укытучы булып эшли. Ул тарих, рус теле, рәсем дәресләре укыта, сыйныф җитәкчесе була. Сыйныфлар арасында үткәрелгән ярышларда җиңеп чыгып Казан шәһәренә путевка белән бүләкләнә. Хезмәтен хөрмәтләп тә бирелгән бүләкләре күп. Мәсәлән, СССР Мәгариф министрлыгының мактау грамотысы (1983 ел 15 декабрь), Тат.АССР Мәгариф министрлыгының мактау грамотасы ( 1989 ел, 3 марты), район буенча унлап мактау грамоталары.

Сунгатуллин Тәлгат Шакир улы җитәкчелек иткән елларда эшләгән укытучылар коллективы, Сультеев Расих, Сультеева Хәлимә, Хайруллина Равия, Шамсутдинова Роза, Бикмуллин Даян, Каюмова Сания, Салимова Роза, Ахметова Венера, Хасанова Венера, Сунгатуллина Фирдәвес, Фахрутдинова Гөлусэ, Сабирова Сария, Ахметова Гөлфирө, Гарипова Гөлфирә, Туктарова Гөлдәрә, Ильясова Ильсөяр, Шарапова Дилә һ.б.

1986 -2017 елларда мәктәп директоры булып Замалетдинов Илдар Миннеислам улы эшләде. Замалетдинов Илдар 1961 елның 3 июлендэ Буа районы Норлат авылында укытучылар гаиләсендә туа. Әтисе – Замалетдинов Миннеислам озак вакыт еллар директор, әнисе – Замалетдинова Глирам – математика укытучысы булып эшлиләр.



1968 елда Камброд авылындагы башлангыч мәктәпкә укырга керә. 1969 елны гаиләсе белән Кул –Черкен авылына күчеп китәләр. 1978 елда  Кул – Черкен урта мәктәбен тәмамлап, КДПИ ның физика – математика факультетына укырга керә. 1982 елда бу уку йортын тәмамлый. Шушы ук елны өйләнә. Хатыны Замалетдинова Галина Павловна, рус теле укытучысы. Ике баласы бар: улы – Наил, кызы – Лииля.

1982 - 1986 елларда Югары Лащи урта мәктәбендә физика һәм математика укытучысы булып эшли. Э 1986 елдан алып бүгенге көнгә кадәр Кайбыч урта мәктәбендә директор булып эшли һәм физика дәресләре алып бара.

Замалетдинов Илдар -  1991 елда «Халык мәгарифе отличнигы» значогы, 2002 елда «За заслуги в образовании» нагрудной знак белән бүләкләнде.

Бугенге көндә Кайбыч мәктәбенә дүрт авылдан килеп балалар укый.: Норлат, Кыр Энәлесе, Югары Наратбаш хэм ин зур олешен Кайбыч балалары алып тора. Кайбыч урта мәктәбендә уку - укыту эшләре буенча директор урынбасарлары булып эшләучеләр:  Султеева Хәлимә Ризатдин кызы. Сабирзянова Фирая, Валиева Фирая Хатыйп кызы, Туктарова Гөлдәрә Хәсән кызы, Хасанова Нурлисә Фирдус кызы, Хөснетдинова Мәрьям Рәуф кызы, хэм бугенге кондэ бу вазифаны башкаручы Сафина Рамилә Рамил кызы.

Безнең мәктәпне тәмамлап, тормышта зур уңышларга ирешкән укучылар да күп. Мәсәлән: Идрисов Г. – академик КГВА, Шакиров Ф. – хирург, Шакиров Р. – академик КГВА, Гарипов авиаинженер, Калимуллин З. – журналист, Камартдинов А. – директор автозавода, Тубэн Новгород, Гафуров И. – Нижнекамск шин заводы директоры, Мортазин Ф. – Татарстанның халык артисы һ.б.

2011 елны мәктәп урта мәктәптән төп мәктәп статусына күчерелде.

2024 нче елда балалар бакчасы мәктәп белән берләштерелде. Балалар бакчасында 4 бала тәрбияләнә. Балалар бакчасында бер тәрбияче, бер мәктәпкәчә белем бирү эшләре буенча директор урынбасары, бер кече тәрбияче исәпләнә.

Бугенге көндә дә мәктәп уңышлы гына үз эшен дәвам итә. 2024-25 уку елында мәктәптә 27 бала белем ала.

Мәктәптә югары белемле 10 укытучы балаларга белем бирә.

Бүгенге көнне мәктәп директоры вазыйфаларын Халиков Айрат Җәүдәт улы башкара. Махмутова А.Р. -уку –укыту мәсьәләләре буенча директор урынбасары. Хасанова Н.Ф..- тәрбия эшләре буенча директор урынбасары. Шулай ук, математикадан – Сафина Р.Р. укыта. Рус теле укытучылары – Кадирова Ф.Н, Хасанова Н.Ф. Татар теле укытучысы – Нургалиева Г.Ф.. Тарих укытучысы – Махмутова А.Р., . Биология – Хасанова Н.Ф.. Физика, география укытучысы– Гилманов М.Т., физик культура дәресләрен Халиков А.З. алып бара. Башлангыч сыйныфларда Музаффарова Р.М., Шарафутдинова Г.И. белем бирәләр. Инглиз телен Сафиуллина Г.Ф. өйрәтә.

Мәктәптә балаларның яхшы белем алып чыгулары өчен барлык шартлар да тудырылган. Бездә спортзал, спорт мәйданы, ашханә, мастерской бар. Мәктәптә төрле кызыклы һәм файдалы китапларга бай китапханә эшләп килә. Шулай ук, мәйданы 1,5 га мәктәп яны участогы бар. Укучылар һәм укытучылар коллективының зур тырышлыклары, хезмәтләре белән монда яшелчә, җиләк – җимеш үстерелә. Мәктәптә ике мәртәбә ашаталар. Күрше авыллардан балаларны мәктәпкә автобус йөртә. Балалар бер сменада укыйлар.